КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1268

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ваклап сату базарлары хакында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2006 ел, 30 декабрь, ФЗ-271 нче Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 ел, 13 июль, 285 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ваклап сату базарлары хакында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2006 ел, 30 декабрь, ФЗ-271 нче Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 ел, 13 июль, 285 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 28 сентябрь, 517 нче; 2010 ел, 22 гыйнвар, 25 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы (кооперация) базарларында сәүдә урынын бирү турында шартнамә төзүнең гадиләштерелгән тәртибе.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы (кооперация) базарларында сәүдә урынын бирү турында шартнамә төзүнең гадиләштерелгән тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы (кооперация) базарларында сәүдә урынын бирү турында шартнамә төзүнең гадиләштерелгән тәртибе»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Сәүдә урыны бирү турында килешү төзүнең гадиләштерелгән тәртибе кулланыла:

авыл хуҗалыгы базарларында – Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә теркәлгән юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм гражданнарга (шул

исәптән гражданнарга-крестьян (фермер) хуҗалыклары башлыклары, шундый хуҗалык әгъзалары, шәхси ярдәмче хуҗалыклар алып баручы яки бакчачылык, яшелчәчелек, терлекчелек белән шөгыльләнүче гражданнарга карата);

авыл хуҗалыгы кооператив базарларында – авыл хуҗалыгы кооператив базары белән идарә итүче авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы әгъзаларына; гражданнарга (шул исәптән гражданнарга-крестьян (фермер) хуҗалыклары башлыкларына, шундый хуҗалык әгъзалары, шәхси ярдәмче хуҗалыклар алып баручы яки бакчачылык, яшелчәчелек, терлекчелек белән шөгыльләнүче гражданнарга карата).»;

3 пунктта «авыл хуҗалыгы (кооператив) базарында» сүзләрен «авыл хуҗалыгы базарында, авыл хуҗалыгы кооператив базарында» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «авыл хуҗалыгы (кооператив) базарында» сүзләрен «авыл хуҗалыгы базарында, авыл хуҗалыгы кооператив базарында» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «авыл хуҗалыгы (кооператив) базарында» сүзләрен «авыл хуҗалыгы базарында, авыл хуҗалыгы кооператив базарында» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «авыл хуҗалыгы (кооператив) базарында» сүзләрен «авыл хуҗалыгы базарында, авыл хуҗалыгы кооператив базарында» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Авыл хуҗалыгы базарында, авыл хуҗалыгы кооператив базарында сәүдә урыны бирү турында шартнамәнең гадиләштерелгән рәвеше гражданнарга, шул исәптән гражданнар – крестьян (фермер) хуҗалыклары башлыкларына, шундый хуҗалык әгъзаларына, шәхси (ярдәмче) хуҗалыкларын алып баручы яки бакчачылык, яшелчәчелек, терлекчелек белән шөгыльләнүче гражданнарга, компаниянең идарә базары карары буенча түләүсез файдалануга бирелергә мөмкин.»;

Гадиләштерелгән тәртипкә кушымтада:

нумерация башисемендә «авыл хуҗалыгы (кооператив) базарында» сүзләрен «авыл хуҗалыгы базарында, авыл хуҗалыгы кооператив базарында» сүзләренә алмаштырырга;

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы базарында, авыл хуҗалыгы кооператив базарында сәүдә урыны бирү турында килешү № ____ (гадиләштерелгән форма)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин